**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О порядке представления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2017 года

### Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящим Законом в соответствии с федеральными законами от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» и от 2 марта 2007 года № 25-ФЗ «О муниципальной службе в Российской Федерации» устанавливается порядок представления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту, а также сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей (далее – сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера).

2. Настоящий Закон не распространяется на отношения, связанные с представлением сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера претендентами на замещение муниципальных должностей, замещение которых осуществляется по результатам муниципальных выборов.

Статья 2. **Порядок и сроки представления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера**

1. Сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера представляются гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту, в порядке, установленном настоящим Законом, по утвержденной в соответствии с федеральным законодательством форме справки.

2. Предусмотренная частью 1 настоящей статьи справка заполняется и представляется Президенту Республики Татарстан посредством специализированного информационного ресурса для подачи сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера (dohod.tatar.ru). Копия указанной справки на бумажном носителе, подписанная гражданами, претендующими на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицами, замещающими муниципальные должности либо должности главы местной администрации по контракту, направляется должностному лицу, уполномоченному по профилактике коррупционных правонарушений в соответствующем муниципальном районе (городском округе), и подлежит хранению в соответствии с законодательством.

3. Если иное не установлено федеральным законом, гражданин, претендующий на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, представляет:

1) сведения о своих доходах, полученных от всех источников (включая доходы по прежнему месту работы или месту замещения выборной должности, пенсии, пособия, иные выплаты) за календарный год, предшествующий году подачи документов для замещения муниципальной должности, должности главы местной администрации по контракту, а также сведения об имуществе, принадлежащем ему на праве собственности, и о своих обязательствах имущественного характера по состоянию на первое число месяца, предшествующего месяцу подачи гражданином документов для замещения муниципальной должности, должности главы местной администрации по контракту (на отчетную дату);

2) сведения о доходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, полученных от всех источников (включая заработную плату, пенсии, пособия, иные выплаты) за календарный год, предшествующий году подачи гражданином документов для замещения муниципальной должности, должности главы местной администрации по контракту, а также сведения об имуществе, принадлежащем им на праве собственности, и об их обязательствах имущест-

венного характера по состоянию на первое число месяца, предшествующего месяцу подачи гражданином документов для замещения муниципальной должности, должности главы местной администрации по контракту (на отчетную дату).

3) сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей по каждой сделке по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций) за отчетный период (с 1 января по 31 декабря), если общая сумма таких сделок превышает общий доход данного гражданина и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду, и об источниках получения средств, за счет которых совершены эти сделки.

4. Лицо, замещающее муниципальную должность либо должность главы местной администрации по контракту, представляет ежегодно, не позднее 30 апреля года, следующего за отчетным периодом:

1) сведения о своих доходах, полученных за отчетный период (с 1 января по 31 декабря) от всех источников (включая денежное вознаграждение, пенсии, пособия, иные выплаты), а также сведения об имуществе, принадлежащем ему на праве собственности, и о своих обязательствах имущественного характера по состоянию на конец отчетного периода (31 декабря);

2) сведения о доходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, полученных за отчетный период (с 1 января по 31 декабря) от всех источников (включая заработную плату, пенсии, пособия, иные выплаты), а также сведения об имуществе, принадлежащем им на праве собственности, и об их обязательствах имущественного характера по состоянию на конец отчетного периода (31 декабря);

3) сведения о своих расходах, а также о расходах своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей по каждой сделке по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций) за отчетный период (с 1 января по 31 декабря), если общая сумма таких сделок превышает общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду, и об источниках получения средств, за счет которых совершены эти сделки.

5. В случае если гражданин, представивший в соответствии с настоящим Законом справки о своих доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, не был наделен полномочиями по муниципальной должности (не был назначен, избран на указанную муниципальную должность), не был назначен на должность главы местной администрации по контракту, эти справки возвращаются ему по его письменному заявлению.

### Статья 3. **Представление уточненных сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера**

1. В случае если гражданин, претендующий на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, лицо, замещающее муниципальную должность либо должность главы местной администрации по контракту, обнаружили, что в представленных ими сведениях о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера не отражены или не полностью отражены какие-либо сведения либо имеются ошибки, они вправе представить Президенту Республики Татарстан уточненные сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера (далее – уточненные сведения) в порядке, предусмотренном настоящим Законом.

2. Гражданин, претендующий на замещение муниципальной должности либо должности главы местной администрации по контракту, вправе представить уточненные сведения в течение одного месяца со дня представления указанных сведений.

3. Лицо, замещающее муниципальную должность либо должность главы местной администрации по контракту, вправе представить уточненные сведения в течение одного месяца после окончания срока, указанного в части 4 статьи 2 настоящего Закона.

### Статья 4. **Ответственность за непредставление сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера либо представление заведомо недостоверных или неполных сведений**

1. За непредставление сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также представление заведомо недостоверных или неполных сведений лица, замещающие муниципальные должности либо должность главы местной администрации по контракту, несут ответственность в соответствии с законодательством Российской Федерации.

2. Факт непредставления сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера или заявление о невозможности по объективным причинам представить сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лицом, замещающим муниципальную должность либо должность главы местной администрации по контракту, подлежит рассмотрению в порядке, устанавливаемом Президентом Республики Татарстан.

Статья 5. **Порядок вступления в силу настоящего Закона и особенности его применения**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

2. Лица, замещающие муниципальные должности и должность главы местной администрации по контракту, представляют с 1 января 2018 года сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера в порядке, установленном настоящим Законом.

3. Органы местного самоуправления, в которые лицами, замещающими муниципальные должности и должность главы местной администрации по контракту, были представлены сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера за 2016 год, направляют указанные сведения на электронном носителе с обеспечением защиты от несанкционированного доступа Президенту Республики Татарстан до 31 декабря 2017 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
19 июля 2017 года
№ 56-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр (алга таба – керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр) тапшыру тәртибен билгели.

2. Әлеге Закон муниципаль сайлаулар нәтиҗәләре буенча биләнә торган муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучылар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыруга бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

**2 статья. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе һәм сроклары**

1. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә федераль законнар нигезендә расланган белешмә рәвешендә тапшырыла.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган белешмә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсы (dohod.tatar.ru) ярдәмендә тутырыла һәм Татарстан Республикасы Президентына тапшырыла. Күрсәтелгән белешмәнең муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан имзаланган кәгазь күчермәсе тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча вәкаләтле вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш була.

3. Федераль законда башкасы каралмаган булса, муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан тарафыннан түбәндәгеләр тапшырыла:

1) муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынында яисә сайланулы вазыйфа биләү урынында алынган керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук граждан муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

2) граждан муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук граждан муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) аларның милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга

кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артыграк булса.

4. Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләр тапшырыла:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына (31 декабрь) милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

2) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук аларның милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм хисап чоры ахырына (31 декабрь) мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артыграк булса.

5. Әлеге Закон нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшырган гражданга муниципаль вазыйфа вәкаләтләре бирелмәсә (күрсәтелгән муниципаль вазыйфага билгеләнеп куелмаса, сайланмаса), ул контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнеп куелмаса, бу белешмәләр аның язмача гаризасы буенча үзенә кире кайтарыла.

3 статья. **Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында төгәлләштерелгән белешмәләр тапшыру**

1. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырылган белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматның булмавын яисә

тулысынча булмавын йә хаталар булуын ачыклаган очракта, алар әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында төгәлләштерелгән белешмәләр (алга таба – төгәлләштерелгән белешмәләр) тапшырырга хокуклы.

2. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан төгәлләштерелгән белешмәләрне күрсәтелгән белешмәләр тапшыру көненнән алып бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

3. Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге Законның 2 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

4 статья. **Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшырмаган йә белә торып ялган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык**

1. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмаган, шулай ук белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

2. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмау факты яисә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне объектив сәбәпләр аркасында тапшырмавы хакында гариза Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе һәм аны куллану үзенчәлекләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыра.

3. Муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан 2016 ел өчен керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшырылган җирле үзидарә органнары күрсәтелгән белешмәләрне,

санкцияләнмәгән файдаланудан сакланышын тәэмин итеп, электрон саклагычта 2017 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Президентына җибәрәләр.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 19 июль
№ 56-ТРЗ